**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

КАРАР

2020 елның 28 сентябре № 6

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районына «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең бюджет процессын оештыру һәм җирлекнең бюджет һәм автоном учреждениеләренең шәхси счетларын ачу һәм алып бару буенча аерым вәкаләтләрен тапшыру турындагы «2020 елның 4 сентябрендәге 291 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турындагы» 2003 елның 6 октябрендагы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 15 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының "Бишнә авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советының 2020 елның 4 сентябрендәге 291 номерлы «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең бюджет процессын оештыру һәм җирлекнең бюджет һәм автоном учреждениеләренең шәхси счетларын ачу һәм алып бару буенча аерым вәкаләтләрен тапшыру турында» гы карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә :

1.1. карарның 1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

1. Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә бюджет процессын оештыру һәм җирлекнең бюджет һәм автоном учреждениеләренең шәхси счетларын ачу һәм алып бару буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Бишнә авыл җирлеге «муниципаль берәмлегенең аерым вәкаләтләрен тапшырырга.

1.2. карарның 3 пунктын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр составында Зеленодольск муниципаль районы информацион сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» информацион телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Бишнә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адресларда урнаштырырга: Бишнә авылы, Үзәк урам, 5 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Мәктәп урамы, 10 йорт ( авыл мәдәният йорты бинасы).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Бишнә авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Бишнә авыл**
**җирлеге башлыгы, Совет рәисе.** **И.М.Фатхуллин**